**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЛЬЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЬЯШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422375 Республика Татарстан,
Тетюшский район с.Льяшево,
ул.Пролетарская, д.22А

422375 Татарстан Республикасы,
Тәтеш
районы, Льяш авылы, Пролетар
ур, 22А

тел., факс (84373) 55-8-26, e-mail: Lsv.tet@tatar.ru
ОКПО 93065268, ОГРН 1061672018210, ИНН/КПП 1638005097/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**06 .03. 2025** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлеге бюджетына салым чыгымнарын стимуллаштыручы һәр салым чыгымы буенча түләүчеләр тарафыннан декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Льяшево авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. http://tetushi.tatarstan.ru/ һәм "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **И.А.Тихонова**